**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**КАРАР**
кырыгынчы утырыш

3 сентябрь 2020 ел **№ 248** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы кайбер норматив – хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив - хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 04 апрелендәге 199 номерлы (26.05.2014 № 210, 15.11.2016 № 67, 20.04.2017 № 84, 19.07.2017 № 90, 12.04.2018 №127, 24.08.2018 № 141, 13.12.2018 № 160, 21.08.2020 № 185, 30.07.2020 №246 карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында (алга таба - Нигезләмә) Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 16 статьясындагы 3 өлешенең 6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.Г. Фәтхуллин